**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 19 май № 356

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 24 октябрь, 792 нче карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацын «Кагыйдәләрне куллану турында аңлатмалар» сүзләреннән соң «, шулай ук республика башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларын юридик-техник рәсмиләштерү буенча методик тәкъдимнәрне эшләү һәм раслау,» сүзләре белән тулыландырырга;

2 пунктта:

икенче абзацта «кабул итү» сүзләрен «бастырып чыгару (кабул итү)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен үтмәгән һәм (яки) бастырылмаган норматив хокукый актларны куллануга юл куймаска;»;

3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы Кагыйдәләрне саклау буенча республика башкарма хакимият органнарын тикшерүләр үткәрергә һәм билгеләнгән тәртиптә җибәрелмәгән норматив хокукый актларны дәүләт теркәвенә соратырга хокуклы.»;

Күрсәтелгән карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 24 октябрь, 792 нче карары көчен югаткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\356.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2002 ел, 18 июль, 426 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 19 май, 356 нчы карары
редакциясендә)

# РЕСПУБЛИКА БАШКАРМА ХАКИМИЯТ ОРГАННАРЫНЫҢ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ АЛАРНЫ ДӘҮЛӘТ ТЕРКӘВЕНӘ АЛУ ҺӘМ БАСТЫРЫП ЧЫГАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## 1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү

1.1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары (алга таба – норматив хокукый актлар) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә һәм аларны үтәү өчен чыгарылалар (кабул ителәләр).

1.2. Республика башкарма хакимият органы тарафыннан чыгарыла (кабул ителә) торган хокукый актлар төрләре бу орган турында нигезләмә белән билгеләнә.

Республика башкарма хакимият органнарының структур бүлекчәләре һәм территориаль органнары норматив хокукый актлар чыгарырга (кабул итәргә) хокуксыз.

1.3. Норматив хокукый актны берничә республика башкарма хакимият органы бергәләп яки, башкалары белән килештереп, берсе чыгарырга (кабул итәргә) мөмкин.

Бергәләп яки башка республика башкарма хакимият органнары белән килештереп чыгарылган (кабул ителгән) норматив хокукый актлар әлеге республика башкарма хакимият органы белән килештереп, үзгәртеләләр яки көчләрен югалтканнар дип танылалар.

1.4. Законнарны мониторинглау барышында үзгәрешләр кертү кирәклеге билгеле булганда элек чыгарылган (кабул ителгән) норматив хокукый актларны яки аларның өлешләрен үзгәртү яки көчен югалткан дип тану турында тәкъдимнәр әзерләнә.

1.5. Норматив хокукый акт текстына элек республика башкарма хакимият органы чыгарган (кабул иткән) норматив хокукый актларны яки аларның өлешләрен үзгәртү яки көчен югалткан дип тану турында нигезләмәләр кертелә.

1.6. Норматив хокукый акт проектына республика башкарма хакимият органында билгеләнгән тәртиптә хокукый экспертиза һәм «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелергә һәм, законнарда билгеләнгән

очракларда, республика башкарма хакимият органының иҗтимагый советында фикер алышынырга тиеш.

1.7. Норматив хокукый акт проекты законнар нигезендә килештерү мәҗбүри булса, шулай ук норматив хокукый актта башка республика башкарма хакимият органнарына кагылышлы нигезләмәләр, нормалар һәм йөкләмәләр булса, мәнфәгатьле республика башкарма хакимият органнары белән килештерелергә тиеш.

1.8. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары һәм дәүләт вазыйфаларын башкаруның административ регламентлары проектларына административ регламентлар системасын эшләү, кертү һәм озата бару белән идарә итүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан экспертиза үткәрелергә тиеш.

1.9. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан норматив хокукый актлар проектларын эшләү республика башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларын юридик-техник рәсмиләштерү буенча методик тәкъдимнәр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу

2.1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, оешмаларның хокукый статусын билгеләүче яки ведомствоара характерда булган норматив хокукый актлар, шул исәптән дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне яки конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

2.2. Норматив хокукый актларны дәүләт теркәвенә алу Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт реестрына алып баручы Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.3. Дәүләт теркәвенә алынырга тиешле норматив хокукый актлар Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына имзаланган көннән соң өч эш көне эчендә тапшырылалар.

2.4. Республика башкарма хакимият органының норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә җибәрүе турында хатына кәгазьдә булган түбәндәге документлар теркәлә:

норматив хокукый актның төп нөсхәсе, аның һәр битенең икенче ягына республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте җитәкчесе имзасы куела;

норматив хокукый актның 3 күчермәсе (дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне яки конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый акт җибәрелгән очракта 1 күчермә тапшырыла);

әгәр башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан карап тикшерүсез чыгарыла (кабул ителә) алмаган норматив хокукый актлар составына керүче норматив хокукый акт дәүләт теркәвенә

тапшырылган очракта, республика башкарма хакимият органы каршындагы иҗтимагый совет бәяләмәсе;

республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте җитәкчесе имзалаган, түбәндәгеләрне үз эченә алган белешмә:

норматив хокукый акт чыгару (кабул итү) турында нигезләр;

әлеге мәсьәлә буенча хокук мөнәсәбәтләренең күрсәтелгән тармагын җайга салучы гамәлдәге норматив хокукый актлар турында белешмәләр һәм аларны кабул ителгән норматив хокукый актка яраштыру вакытлары хакында мәгълүмат;

норматив хокукый актны мәнфәгатьле республика башкарма хакимият органнары һәм башка дәүләт органнары белән килештерү турында белешмә, әгәр мондый килештерү мәҗбүри булса;

норматив хокукый актка коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез һәм иҗтимагый экспертиза үткәрү турында белешмәләр;

норматив хокукый актны эшләүне гамәлгә ашырган вазыйфаи зат турында белешмәләр, телефон номерын күрсәтеп.

Бергә теркәп җибәрелгән хат түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

әлеге Кагыйдәләрнең 3.2.1 пунктында каралган очракта, теркәлгән норматив хокукый актны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгаруга түләү гарантиясен;

әлеге Кагыйдәләрнең 3.2.2 пунктында каралган очракта, теркәлгән норматив хокукый актны татар теленә тәрҗемә итү гарантиясе.

2.5. Берничә республика башкарма хакимият органы бергә чыгарган норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә тапшыру норматив хокукый актны чыгаручылар (кабул итүчеләр) арасында беренче күрсәтелгән органга йөкләнә.

2.6. Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу түбәндәгеләрне үз эченә ала:

норматив хокукый актның законнарга ярашуына хокукый экспертизаны;

норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында яисә дәүләт теркәвенә алудан баш тарту хакында карар кабул итүне;

теркәү санын бирүне;

норматив хокукый актны Республика дәүләт идарәсе органнарының норматив хокукый актлары дәүләт реестына кертүне.

2.7. Норматив хокукый актларны дәүләт теркәвенә алу әлеге Кагыйдәләрнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән бергә теркәп җибәрелгән хатны теркәүгә алу датасыннан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 15 көн эчендә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бергә теркәп җибәрелгән хатны теркәүгә алу бергә теркәп җибәрелгән хат һәм документлар кәгазьдә кергән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан башкарыла.

Норматив хокукый акт дәүләт теркәвенә алу вакыты Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыкка түгел.

2.8. Әгәр юридик экспертиза үткәргәндә норматив хокукый актның законнарга ярашмавы билгеле булса, норматив хокукый актны теркәүгә алудан баш тартыла.

2.9. Дәүләт теркәвенә алудан баш тартылган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы әлеге Кагыйдәләрнең 2.7 пунктында каралган вакыт эчендә, баш тартуның сәбәбен язмача күрсәтеп, аларны чыгарган (кабул иткән) органга кире кайтара.

2.10. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы норматив хокукый актны тиешле мөрәҗәгать нигезендә, теркәүгә алмыйча, шулай ук әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә тапшыру тәртибен үтәмәгән очракта республика башкарма хакимият органына кире кайтара ала.

2.11. Әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән дәүләт теркәвенә тапшыру тәртибен үтәмәгәндә норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алмыйча кире кайтару очрагында бозулар бетерелергә, ә норматив хокукый акт республика башкарма хакимият органы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының норматив хокукый актны кире кайтару турында хатын алган көннән соң 30 көн эчендә кабат дәүләт теркәвенә тапшырылырга тиеш.

2.12. Дәүләт теркәвенә алган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча норматив хокукый актның төп нөсхәсенә теркәү санын биреп, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә тапшырган республика башкарма хакимият органына җибәрә.

2.13. Элек теркәлгән норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый актлар әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

## 3. Республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын бастырып чыгару

3.1. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган норматив хокукый актлар билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырылып чыгарылырга тиеш, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне яки конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш.

3.2. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми бастырылып чыгарылырга тиеш норматив хокукый актлар күчермәләре түбәндәгеләргә җибәрелә:

3.2.1. Норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы тарафыннан «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләренә, әгәр норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы тарафыннан аны күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару турында карар кабул ителсә.

Норматив хокукый актны бастырып чыгару чыгымнарын норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы тота.

Норматив хокукый актны берничә республика башкарма хакимият органы бергә чыгарганда (кабул иткәндә) чыгымнар аларны чыгарган (кабул иткән) органнар белән килештерелеп түләнә;

3.2.2. Норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы тарафыннан Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына, әгәр әлеге орган бу норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру турында кара кабул итсә.

Рәсми бастырып чыгарылырга тиешле норматив хокукый актлар күчермәләре, дәүләт теркәвенә алыну турында тамга белән норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органнары тарафыннан рус һәм татар телләрендә электрон рәвештә PDF форматында Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына тапшырылалар.

Рәсми бастырып чыгарылырга тиешле норматив хокукый актлар күчермәләрен Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында урнаштыруны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы түләүсез нигездә башкара.

Урнаштырыла торган норматив хокукый актның электрон күчермәсе эчтәлеге төп нөсхә текстына тәңгәл булуы өчен норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы җаваплы була;

3.2.3. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары җыентыгы» журналы редакциясенә.

3.3. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт теркәвенә алынганнан соң 10 көн эчендә бастырып чыгарылырга тиеш.

Норматив хокукый актны бастырып чыгарганда һәм таратканда дәүләт теркәвенә алу санын һәм вакытын күрсәтү мәҗбүри.

3.4. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт теркәвенә алырга кирәкми дип табылган норматив хокукый акт норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш. Бу чакта күрсәтелгән норматив хокукый актның законлы көченә керү тәртибен норматив хокукый актны чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органы билгели.

3.5. Әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән һәм бастырып чыгарылмаган республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актлары кулланылырга тиеш түгел.

___